# Егет булсаң, егетлек күрсәт илгә

(Г. Утыз Имәни)



# Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгариның тууына 260 ел

# Язучының тормыш юлы

Габдерәхим Утыз Имәни (аның тулы исеме – Габдерәхим бине Госман бине Сәрмәки бине Кырыйм Утыз Имәни әл-Болгари) 1754нче елда хәзерге Татарстан Республикасы Чирмешән районы Утыз Имән авылында крестьян гаиләсендә туа. Аның әтисе Госман чыгышы белән хәзерге Лениногорск районының Тимәш авылы кешесе, ә әнисе Гафифә Утыз Имән авылы кызы булып, өйләнешкәннән соң алар Тимәш авылында тора башлыйлар. Ләкин Габдерәхим туганчы ук әтисе Госман үлеп китә. Ярдәмчесез калган яшь хатын туган авылына кайта һәм шунда үзенең әтисе йортында Габдерәхимне таба. Ике-өч ел үтми, ул үзе дә дөнья куя. Шулай итеп, Габдерәхим, сабый чагыннан ук ата-анадан ятим калып, туган тиешле бер җиңгәсе кулында тәрбияләнә.

Укырга, белем алырга омтылыш Габдерәхимдә бик иртә уяна. Башта ул үз авылында Вилдан мулла мәдрәсәсенә йөреп укый, аннары мәдрәсәдәге вак-төяк хезмәтләрне үтәп үз-үзен карардай яшькә җиткәч, бөтенләй мәдрәсәгә яшәргә күчә. Зирәклеге, үткен зиһенлеге белән ул сабакташлары арасында бик тиз "Укымый белә торган шәкерт"кә әйләнә һәм озакламый үзенең яшьтәшләре нә хәлфәлек итә башлый. Вилдан мулла мәдрәсәсеннән соң Габдерәхим берничә ел күрше –тирә авыл мәдрәсәләренә барып укый.



Габдерәхимне «укымый белә торган шәкерт» дип йөрткәннәр

# Урта Азиядә яшәгән еллар (1788-1798нче еллар)


- Габдерәхим Утыз Имәни (аның тулы исеме – Габдерәхим бине Госман бине Сәрмәки бине Кырыйм Утыз Имәни әл-Болгари) 1754нче елда хәзерге Татарстан Республикасы Чирмешән районы Утыз Имән авылында крестьян гаиләсендә туа. Аның әтисе Госман чыгышы белән хәзерге Лениногорск районының Тимәш авылы кешесе, ә әнисе Гафифә Утыз Имән авылы кызы булып, өйләнешкәннән соң алар Тимәш авылында тора башлыйлар. Ләкин Габдерәхим туганчы ук әтисе Госман үлеп китә. Ярдәмчесез калган яшь хатын туган авылына кайта һәм шунда үзенең әтисе йортында Габдерәхимне таба. Ике-өч ел үтми, ул үзе дә дөнья куя. Шулай итеп, Габдерәхим, сабый чагыннан ук ата-анадан ятим калып, туган тиешле бер җиңгәсе кулында тәрбияләнә.
- Укырга, белем алырга омтылыш Габдерәхимдә бик иртә уяна. Башта ул үз авылында Вилдан мулла мәдрәсәсенә йөреп укый, аннары мәдрәсәдәге вак-төяк хезмәтләрне үтәп үз-үзен карардай яшькә җиткәч, бөтенләй мәдрәсәгә яшәргә күчә. Зирәклеге, үткен зиһенлеге белән ул сабакташлары арасында бик тиз “Укымый белә торган шәкерт”кә әйләнә һәм озакламый үзенең яшьтәшләре нә хәлфәлек итә башлый. Вилдан мулла мәдрәсәсеннән соң Габдерәхим берничә ел күрше –тирә авыл  мәдрәсәләренә барып укый.



- Оренбург өлкәсенең Каргалы авылында икенче мәчет каршындагы Вәлид бине Мөхәммәд әл-Әмин мәдрәсәсендә шагыйрь атаклы ишан Вәлид Каргалыйдан  белем ала.



Утыз Имәни 1788нче елда, 34 яшендә, үзенең гаиләсен һәм балаларын ияртеп, Бохарага укырга киткән.



Бохарадан соң Сәмәркандта булган



Тестлар эшләргә.

# Казан мәчете